АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.07.2020 п.г.т. Алексеевское № 332

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районында**
**муниципаль хезмәт турында**
**Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә вазыйфаи затларның аерым категорияләренең катнашу тәртибен камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 07 маендагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 маддәсенә үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 21 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 2018 елның 14 сентябрендәге 193 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

1) 12.1 пунктындагы 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә катнашырга:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия идарәсендә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте турында Кодекснын $16^1$ маддәсендә билгеләнгән тәртиптә

алынган яллаучы вәкиле рөхсәте белән коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия идарәсендә катнашудан тыш) түләүсез нигездә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тапшыру;

г) муниципаль берәмлекнең идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә оештыруны, гамәлгә куючысы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә тапшыру;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

е) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә.».

2) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәнең 16 маддәсендәге 16,3 пунктының 6 пунктчасына үзгәреш кертергә, «мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы» сүзләрен «индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Совет рәисе урынбасары Г.В. Беловага йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль**
**районы башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**